ДҮШӘМБЕ
8 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 6 (5806)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ХЕЗМӘТ ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕГЕН ТАГЫН ДА КҮТӘРҮ ӨЧЕН!

Хезмәтнең югары җитештерүчәнлеге—коммунизмга баруның иң әһәмиятле шартларының берсе. СССР ның төп экономик бурычын хәл итү өчен социализмның хезмәт җитештерүчәнлеге, капитализмның хезмәт җитештерүчәнлегенә караганда, югары булырга тиеш. „Димәк... бездә хезмәтнең җитештерүчәнлеге никадәр югары булса, бездә производство техникасы никадәр яхшыра барса, бу иң әһәмиятле экономик бурычны шул кадәр тизрәк үтәргә мөмкин булачак, бу бурычны үтәү срокларын шул кадәр күбрәк кыскартырга мөмкин булачак“ (Сталин).

Пролетар революциянең бөек даһилары Ленин һәм Сталин безнең халык хуҗалыгыбызда хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү мәсьәләсенә аеруча зур әһәмият бирделәр. Иптәш Сталин бу мәсьәләне хәзер дә игтибар үзәгенә куя. Ул, безнең промышленностыбызның яңа шартларда эшләвенә карата үзенең мәшһүр алты шартында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү турында болай дигән иде:

„Эшчеләрне тагын шундый хезмәт шартларына куярга кирәк ки, ул шартлар аларга төшенеп эшләргә, җитештерүчәнлекне күтәрергә, продукциянең сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирерлек булсыннар“.

Бу шарт, бу тарихи күрсәтмә хәзерге көн өчен дә үзенең көчен һич тә югалтканы юк! Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү, төшенеп эшләү, продукциянең сыйфатын яхшырту бүгенге көн өчен дә үзәк мәсьәлә булып торалар. Илебезнең алдынгы кешеләре—стахановчылар хезмәт җитештерүчәнлеген һаман югары күтәрә баралар.

Москва шәһәрендәге инструменталь завод коллективы хезмәт җитештерүчәнлегенең **бишьеллык планын дүрт елда үтәү йөкләмәсен алды** һәм үзләре белән тиңләшергә СССР дагы барлык машина төзелеше предприятиеләренең коллективларына мөраҗәгать итте.

Бу чакыру машина төзелеше предприятиеләренең коллективлары тарафыннан гына түгел, бәлки илебезнең барлык заводларында һәм фабрикаларында да зур күтәренкелек белән каршы алына.

Татарстанның байтак предприятиеләре яңа елның—1940 нчы елның беренче эш көннәрен хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрү белән башлап җибәрделәр. Алар моның белән Москвадагы инструменталь заводы коллективының чакыруына җавап бирәләр. Социалистик төзелеш тарихына 1940 нчы елның яңа матур сахифәләр язуы өчен омтылалар, илебезнең экономик һәм оборона куәтен арттыру өчен яңа вкладлар салалар.

Сталинчыл өченче бишьеллык планының хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәткечләрен дүрт елда тулы үтәү мөмкин икәнлеген үткән ике елның эш нәтиҗәләреннән дә ачык күреп була.

Мәсәлән, Вахитов исемендәге жиркомбинатта халык хуҗалыгының өченче бишъеллык планы буенча бер эшче 1942 нче елда 33 мең 262 сумлык продукция җитештерергә тиеш. Ә комбинатта исә инде бер эшче 1939 нчы елны ук 41 мең 10 сумлык продукция җитештерде; 40 нчы елны ул 43 мең 366 сумга җитәргә тиеш. Бу санны 1937 нче елны бер эшче җитештергән 23 мең 500 сум белән чагыштырганда, үсешнең гаять зур икәнлеген күрәбез. Яки менә Татарстанның Азык промышленносты наркоматын алыйк. Наркомат буенча өченче бишъеллыкта хезмәт җитештерүчәнлеге 36,7 процентка күтәрелергә тиеш. Ә үткән елгы 11 айда уртача үсеш 11,5 процент булды.

Мехкомбинатта хезмәт җитештерүчәнлеге 1938 нче елда, 1937 нче елгы планга чагыштырганда, 14 процентка, 1939 нчы елда 24 процентка күтәрелде.

Бу саннар безнең Татарстан промышленностында да хезмәт җитештерүчәнлегенең ел саен үсә баруын күрсәтәләр. 1939 нчы елның соңгы кварталы бу тармакта тагын да күп алга китүне тәэмин итте. 1940 нчы ел хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә барлык предприятиеләрдә дә яңа уңышлар бирергә тиеш. Аеруча, Серго Орджоникидзе исемендәге завод, Судноларга ремонт ясау буенча Максим Горький исемендәге һәм Чистай заводлары, „Красный Путь“ заводы һәм Серго исемендәге завод хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә үрнәк күрсәтергә тиешләр. Москваның инструменталь заводы коллективы чакыруына кушылып эшләүдә алдынгы сафта барырга тиешләр.

Москваның инструменталь заводы коллективы хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең практик юлларын ачык итеп күрсәтте.

Беренче—стахановчылык хәрәкәтен һәм аның яңа формасы булган күп станокларда эшләүчеләр һәм бер үк вакытта күп профессияләрне башкаручылар сафын киңәйтү.

Икенче—бракны кискен рәвештә киметү; эшсез торуларны бетерү һәм эш сәгатьләреннән тулысынча файдалану; бер генә минутны да, бер генә секундны да бушка үткәрмәү.

Өченче—станокларны автоматлаштыру.

Дүртенче—цехларда рационаллаштыруны кертү һәм технологик процессларны яхшырту.

Бишенче—искергән нормаларны яңадан карау һәм аларны җитештерүнең алдынгы нормалары белән алыштыру.

Производство планын үтәү өчен көрәшкә большевистик җитәкчелек иткәндә, 1940 нчы ел планын, эшчеләр саны аз булганда да тулысынча һәм арттырып үтәүгә мөмкинлекләр зур. Төп бурыч—**аз эшчеләр белән күп продукция бирүдән гыйбарәт!** Шунлыктан эшчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен эш урыннарын яхшы оештырырга, эшчеләрнең квалификацияләрен күтәрергә, аларга техниканы үзләштерүгә ярдәм итәргә һәм көнкүреш шартларын нык лап яхшыртырга кирәк.

„Хезмәт җитештерүчәнлеген чынлап, социалистик җәмгыятькә лаеклы итеп күтәрү өчен көрәш нәрсә дигән сүз ул? Иң элек, хезмәтне шулай итеп оештырырга кирәк ки, дөньяда иң кыска эш көнен—420 минут вакытны тулы файдаланырга, минутларны гына түгел, сикундларны да санарга өйрәнергә, производство эшен туктаусыз яхшыртырга, кеше хезмәтен әрәм итүгә каршы рәхимсез көрәшергә кирәк дигән сүз.

Аннан соң, ул, производство материалларын—чималны, ягулыкны, электроэнергияне экономия белән тоту дигән сүз“. („Правда“).

Хезмәтнең җитештерүчәнлеген күтәрү өчен көрәштә производство командирларының эш стиле әнә шушы нигезгә корылырга тиеш. 1940 нчы ел беренче көннәрендә үк уңышлы адымнар белән алга китсен өчен, елны уңышлы тәгәлләү өчен көнлек, декадалык, айлык һәм квартал планнарын өзлексез үтәп барыйк!

Сталинчыл Өченче Бишъеллык исемендәге социалистик ярыш белән барлык эшчеләрне, колхозчыларны һәм интеллигентларны чолгап алыйк!

1940 нчы елны хезмәт җитештерүчәнлегенең бишъеллык планын дүрт елда үтәү өчен хәл иткеч җиңүләргә ирешү елы итик!



15 нче декабрьдә Арктика флотының флагман бозваткычы „И. Сталин“ партия һәм хөкүмәтнең кушуы буенча „Седов“ бозваткычын һәм аның батыр кешеләрен бозлар арасыннан чыгару өчен Мурманскидан походка чыгып китте. РӘСЕМДӘ: „И. Сталин“ бозваткычы Мурманск портында почетлы рейскә чыгар алдыннан.

Д. Дебабов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

„СЕДОВ“КА ҖИТӘРГӘ 5 МИЛЬ КАЛДЫ

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ БОРТЫ, 6 гыйнвар. (Радио. ТАСС). Аз гына аяза башлагач ук 2 сәгаттә без яңадан „Седов“ка таба бара башладык. Бер сәгат ярым вакыт эчендә зур боз өемен аркылы үттек. 3 сәгат 50 минутта тоташ боз кырында аз гына булса да ярылу башлануны көтеп машиналарны туктаттык. Горизонтта күренү яхшыра башлады.

Сәгат 5 тә вахта рулевое иптәш Полухин 5 миль чамасы ераклыкта, нак бозваткыч борны турында гына „Седов“ның җемелдәп торган сары утын күрде.

Седовчылар әле яңа гына безгә үзләренең ана аю үтергәнлекләрен, ә аю балаларын тере килеш тотканлыкларын белдерделәр.

Бозваткычтагылар берсе дә йокламый.

И. Папанин.

Белоусов белән Бадигин арасында сөйләшү

„**И. Сталин**“ **бозваткычы**, 5 гыйнвар. (Радио. ТАСС). Бүген 5 нче гыйнварда, 18 сәгат 45 минутта, „И. Сталин“ бозваткычының капитаны иптәш Белоусов белән „Г. Седов“ бозваткычының капитаны иптәш Бадигин арасында радио буенча сөйләшү булды. Сөйләшүнең эчтәлеген тапшырам:

БЕЛОУСОВ: Исәнме, Константин Сергеевич! Бүген яңадан үтәргә маташтым, ләкин һәр вакыт диярлек бары көнчыгышка яки көнбатышка таба гына бардык. Төньякка таба юнәлештә һәр вакыт зур һәм киселмәслек боз кисәкләренә очрадым. 1—1,5 миль алга киттек. Күмерне әрәм итмәү өчен яңадан туктарга туры килде. Бездә һава шактый елынды—температура минус 3 градус. Җил—7 балл көч белән көньяк-көнчыгышка исә. Без астрономия юлы белән урныбызны билгеләдек, һәм „Седов“ пеленгы белән чагыштырып түбәндәге саннарны алдык: киңлек—80 градус 35 минут, озынлык безгә бүген хәбәр ителгәнчә. 19 сәгаттә прожектор яктыртам. Нурларның күренүен хәбәр итегез. Без көнчыгышка таба бер миль чамасы алга киттек, ә пеленг 7 градуска үзгәрде, ягни без бөтенләй якынайдык инде. Прожекторларның күренүе турында хәбәр итү белән бергә, „Седов“ районында һаваның температурасын хәбәр итегез. Сәлам!

БАДИГИН: Хәерле кич, Михаил Прокофьевич. Берничә сәгат инде прожекторлар яхшы күренәләр. Хәзер без күрә торган яктылык бездән туп туры көньякта. Сөйләшүебездән соң нак 5 минут чамасы үткәч мачтада лампа кабызырмын. Бездә дә һава елынды: температура минус 4 градус. Җил 5—6 балл көч белән көнчыгыштан көньякка исә. 10 сәгаттә күзгә күренерлек ераклыкта бозлар ярыла башлады. Аларның күбесе бөтен горизонт буйлап төньякка һәм көньякка таба юнәлгән. Кайбер урыннарда ачык сулы урыннар күренә. Хәзер „Седов“ның уң як бортыннан 11 метр ераклыкта 2 метр зурлыгында боз ярыгы бар. Хәзер сездә дә бераз боз ярыла башлар дип уйлыйм. Хәзергә координатлар юк—йолдызлар күренми.

Берничә минуттан соң иптәш Бадигин телеграф буенча түбәндәгеләрне хәбәр итте:

„Хәзер бездә лампа яндырылган, сезне бик аз гына күрә башладык, шулай да күрәбез“.

Флагман, сулы урыннарны капшап, пеленг буенча „Седов“ка таба бара. 21 сәгат 30 минутта яңадан көчле бозлар арасына килеп кердек, бозлар өелә. Буран башланды, күренү кыенлаша.

И. Папанин.

Япония сәүдә делегациясе җитәкчесе Мацусима Сикао әфәндене иптәш Молотовның кабул итүе

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотов 5 нче гыйнварда Япония сәүдә делегациясе җитәкчесе Мацусима Сикао әфәндене кабул итте. Кабул итүдә Япониянең Москвадагы илчесе Того әфәнде һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары урынбасары иптәш С. А. Лозовский булдылар.

Советлар Союзы белән Болгария арасында сәүдә договоры төзү

Сөйләшүләр уңышлы тәмам булганнан соң 1940 нчы елның 5 нче гыйнварында Москвада, Советлар Союзы белән Болгария арасында сәүдә һәм диңгездә йөзү турында 3 еллык сроклы договорга һәм 1940 нчы елгы товар әйләнеше һәм түләүләр турындагы килешүгә кул куелды.

Сәүдә договоры ике арада иң күп уңайлылык принципын куллануны күздә тота.

1940 нчы елгы товар әйләнеше турындагы килешү СССР белән Болгария арасында товар әйләнешен шактый киңәйтүне күздә тота. Бу килешү буенча 1940 нчы елны гомуми товар әйләнеше 920 миллион лев сумасында булачак.

Советлар Союзы Болгариядән дуңгызлар, дөге, күн чималы, тәмәке, роза мае һәм башка товарлар кертүне, ә Болгариягә авыл хуҗалыгы машиналары, кара металлар, нефть продуктлары, ашламалар, химикалийлар, целлюлоза, мамык һәм башка товарлар чыгаруны күздә тота.

Советлар ягыннан сәүдә һәм диңгездә йөзү турындагы договорга һәм товар әйләнеше һәм түләүләр турындагы килешүгә ССР Союзы Тышкы Сәүдә Халык Комиссары иптәш **А. И. Микоян**, Болгария ягыннан Болгариянең финанс министре **Божилов** әфәнде кул куйдылар.

(ТАСС).

ХРОНИКА

СССР Верховный Советы Президиумы 1940 нчы елның 5 нче гыйнварында СССР белән Кытай республикасы арасында 1939 нчы елның 16 нчы июнендә Москва шәһәрендә төзелгән сәүдә договорын ратификацияләнде.

Чунцин, 6 гыйнвар. (ТАСС). 1939 нчы елның 16 нчы июнендә Москва шәһәрендә СССР белән Кытай арасында төзелгән сәүдә договоры Кытайның законнар чыгару палатасы тарафыннан ратификацияләнде.

МТС ҺӘМ МТМ АЛДЫНГЫЛАРЫНЫҢ

РЕСПУБЛИКА ПОЧЕТ ТАКТАСЫ

Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда отлично күрсәткечләр биргән алдынгылар һәм стахановчылар ВКП(б) райкомнарының һәм хезмәт ияләре депутатлары район советлары башкарма комитетларының күрсәтүләре буенча Республика Почет тактасына кертеләләр:

6. Тымытык районының **Тымытык МТС ы**—тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1940 нчы елның 1 нче гыйнварына тулысынча тәгәлләде (МТС директоры иптәш Галәветтинов, директорның политик эшләр буенча урынбасары иптәш Фаттахов, МТС ның өлкән механигы иптәш Рахманкулов).

7. Теләче районының **Теләче МТС ы**—тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1940 нчы елның 1 нче гыйнварына тулысынча тәгәлләде (МТС директоры иптәш Шәймәрдәнев, директорның политик эшләр буенча урынбасары иптәш Таһиров, МТС ның өлкән механигы иптәш Сибиряков).

8. Биләр районы, Биләр МТС ының трактор бригадасы бригадиры иптәш **Б. Җиһаншин**—үз бригадасындагы тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1939 нчы елның 15 нче декабренә тулысынча тәгәлләде.

9. Актаныш районы, Актаныш МТС ының тракторчылары һәм эшчеләре: слесарь **Сәрвәрев, токарь И. Ляпустин,** поршеннар группасы бригадиры **Габдрахманов,** арткы күперләргә ремонт ясау бригадасы бригадирының ярдәмчесе Хәбиев, подшипникларга реставрация ясау бригадасы бригадирының ярдәмчесе **С. Сабиров** иптәшләрне. Алар көнлек норманы 175—200 процент үтиләр.

КОНКРЕТ ЙӨКЛӘМӘЛӘР

Москвадагы инструменталь заводы коллективының мөраҗәгате Серго исемендәге заводның барлык цехларында тикшерелде. Заводның эшчеләре, инженер-техник-работниклары һәм хезмәт кәрләре Москва инструментальщикларының инициативасын зур күтәренкелек белән каршылыйдылар. Җыелышларда катнашучы эшчеләр, партиянең XVIII нче съезды тарафыннан илебез алдына куелган төп бурычны—алдынгы капиталистик илләрне экономик яктан якындагы 10—15 ел эчендә куып җитү һәм узып китү бурычын хәл итүдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү зур урын тотуы турында күрсәттеләр.

Цех начальнигы иптәш Кузьмин үз чыгышында болай ди:

— Безнең цех 1939 нчы елда хезмәт җитештерүчәнлеген, 1938 нче елга караганда, 43 процентка күтәрде. Бу үсеш үткән елның 4 нче кварталында бигрәк тә югары булды. Күп станокта эшләү, бер үк вакытта берничә профессия буенча эшләү методларын киң куллану нәтиҗәсендә, хезмәт җитештерүчәнлеге 4 нче кварталда, III нче кварталга караганда, 19 процентка үсте. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү мөмкинлекләре бездә тагын да күбрәк иделәр. Ләкин без алардан тулысынча файдалана белмәдек. Бездә брак та байтак булды. Цех инструментлар белән, ярым фабрикат белән үз вактында тәэмин ителмәде. Әгәр дә мондый кимчелекләр булмаса, хезмәт җитештерүчәнлеге тагын да күтәрелгән булыр иде.

Заводның барлык эшчеләре инструментальщикларның чакыруына кушылдылар, конкрет йөкләмәләр алдылар, үзара ярыша башладылар.

Иптәш Кузьмин җитәкчелек итә торган цех коллективы бракны 50 процентка киметү, эшсез торуларны булдырмау, ремонт эшләрен тиз үткәрү йөкләмәсен алды. Күп станокчылар һәм бер үк вакытта берничә профессия буенча эшләүчеләрнең санын ике тапкыр арттыру, социалистик ярышны киң җәелдерү, производствоның технологик процессларын яңарту исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген 25 процентка күтәрү йөкләмәләрен алды.

Ике станокта эшләүче стахановчы иптәш Маслов хезмәт җитештерүчәнлеген 50 процентка күтәрү белән, еллык планны Октябрьнең XXIII еллыгына үтәүне бурыч итеп куйды. Ике токарь станогында эшләүче стахановчы—комсомолец иптәш Файзуллин да шундый ук йөкләмәләр алды.

Б. Камалов.

Мехкомбинатның хуҗалык работниклары активы киңәшмәсе

5 нче гыйнварда Казан Мехкомбинаты фабрикаларында эшләүче хуҗалык работникларының активы киңәшмәсе булып үтте. Җыелышта ВКП(б) ның Өлкә Комитеты секретаре иптәш Алемасов, ВКП(б) ның Казан шәһәре Комитеты секретаре иптәш Бычков, Сталин райкомы секретаре иптәш Зайцев һәм Главко вәкиле иптәш Рыбаков катнаштылар.

Киңәшмәдә Мехкомбинатның 1939 нчы ел эш йомгаклары һәм 1940 нчы елда алда торган бурычлар турында комбинат директоры иптәш Барышниковның доклады тыңланды.

Казанның барлык мех фабрикалары 1939 нчы ел планын срогыннан элек үтәделәр. 2 нче һәм 4 нче номерлы мех фабрикаларында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм продукциянең сыйфатын яхшырту өлкәсендә бигрәк тә зур уңышларга ирешелде. Комбинат буенча продукциянең үзенә төшү бәясе планга караганда 2,5 процент киметелде. Рационализация һәм уйлап табулардан 63 такдим тормышка ашырылып, 1 миллион сумнан артык файда алынды. Үткән елгы планны үтәү буенча Казан Мехкомбинаты СССР мехпромышленностында алдынгылыкны яулап алды.

Ләкин бу уңышлар әле мехфабрикалары эшендә җитешсезлекләр юк дигән сүз түгел. Монда стахановчылык хәрәкәтенә, социалистик ярышка җитәкчелек итүдә зур кимчелекләр бар. Аерым фабрикаларда продукциянең сыйфаты начар. Мәсәлән, 3 нче фабрикада эшләнгән продукциянең сыйфаты бик түбән була. Җитештерелгән продукциянең 12—13 проценты кат-кат төзәтелә. Аның өчен күп сума тотыла һәм күп эш вакыты әрәм була.

Доклад буенча сөйләүләргә 19 кеше катнашты.

Иптәш Винокуров үзенең чыгышында болай диде:

— Безнең фабрикаларыбызда хезмәт җитештерүчәнлеге елданел арта. 1936 нчы елда бер эшче 17 мең сумлык продукция эшләгән булса, 1939 нчы елны 25 мең 600 сумлык продукция бирде. Бу, бездә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен мөмкинлекләрнең зур булуын күрсәтә.

Ләкин безнең кайбер хуҗалык работникларыбыз мөмкинлекләрдән тиешенчә файдаланмыйлар. Мәсәлән, мехкомбинат фабрикаларында эшләүчеләр арасында бары тик 9 гына кеше күп станокта эшли. Стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек итү дә яхшы түгел. Менә бер факт. Әгәр дә 1939 нчы елның 1 нче гыйнварына эшчеләрнең 57,2 проценты стахановча эшләгән булса, хәзер бездә алар 55 проценттан артмый. Шунлыктан, хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча 5 еллык планны 4 елда, яки аннан да кимерәк вакыт эчендә үтәү өчен стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек итүне яхшыртырга кирәк.

Актив комбинат тарафыннан фабрикаларга җитәкчелекнең конкрет, оператив булмавы турында күрсәтте. Диспетчерлар эшендәге һәм механика булегендәге җитешсезлекләр каты тәнкыйть астына алынды.

Актив җыелышы комбинатның 1940 нчы елда тагын да яхшырак эшләве өчен бөтен мөмкинлекләре барлыгын әйтте, алардан файдалану өчен конкрет юллар күрсәтте.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

5 нче гыйнварда барлык юнәлешләрдә дә әйтерлек бер нәрсә дә булмады.

Ухта, Реболы һәм **Петрозаводск** юнәлешләрендә разведчикларның күзәтүләре барды. **Петрозаводск** юнәлешендә безнең разведка тарафыннан дошманның 50 кешелек группасы юк ителде.

Карелия бугазында разведка күзәтүләре һәм артиллериядән атышулар барды.

Безнең авиация дошманның резервларына һәм хәрби объектларына берничә уңышлы сугыш налетлары ясады.

6 нчы гыйнварда фронтта әйтерлек бер нәрсә дә булмады. **Ухта** юнәлешендә разведка отрядларының бәрелешләре булды. **Реболы һәм Петрозаводск** юнәлешләрендә разведчикларның күзәтүләре һәм мылтыклардан-пулеметлардан атышулар барды. **Карелия** бугазында разведчикларның күзәтүләре һәм артиллериядән атулар булды.

Безнең авиация дошманның резервларына һәм хәрби объектларына берничә уңышлы атакалар үткәрде. Һава сугышында дошманның 10 самолеты бәреп төшерелде.

Хезмәт ияләре депутатларының край, өлкә, округ, район, шәһәр, авыл һәм поселкы Советларына

САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА

(САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДАГЫ САННАР ӨЛКӘ ҺӘМ КРАЙ БАШКАРМА КОМИТЕТЛАРЫННАН, АВТОНОМИЯЛЕ ҺӘМ СОЮЗНЫЙ РЕСПУБЛИКАЛАРНЫҢ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЛАРЫ ПРЕЗИДИУМНАРЫННАН СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ СЕКРЕТАРИАТЫНА АЛЫНГАН МАТЕРИАЛЛАР БУЕНЧА ИГЛАН ИТЕЛӘ)

1939 нчы елның 24 нче декабрендә РСФСР да, Украина ССР да, Белоруссия ССР да, Грузия ССР да, Әрмәнстан ССР да, Төркмәнстан ССР да, Казагыстан ССР да һәм Кыргызстан ССР да һәм 1939 нчы елның 29 нчы декабрендә—Азербайҗан ССР да, Үзбәкстан ССР да һәм Тажикстан ССР да хезмәт ияләре депутатларының край, өлкә, округ, район, шәһәр, авыл һәм поселкы Советларына сайлаулар булды.

Карелия АССР дан һәм Дагстан АССР ның биек таулы 5 районыннан башка, хезмәт ияләре депутатларының барлык җирле Советларына сайлаулар үткәрелде. Карелия АССР Верховный Советы Президиумының карары буенча Карелия АССР да сайлаулар кичектерелде, Дагстан АССР Верховный Советы Президиумының карары буенча Дагстан АССР ның биек таулы 5 районында сайлаулар 1940 нчы елның май-июнь айларына күчерелде.

Барлыгы хезмәт ияләре депутатларының 6 край советы, 88 өлкә советы, 9 өлкә советы (автономияле өлкәләрдә), 21 округ советы, 3.572 район советы, 912 шәһәр советы, шәһәрләрдә 389 район советы, 63.183 авыл һәм поселкы советы сайланды.

Союзный республикалар буенча аерым алганда хезмәт ияләре депутатларының сайланган җирле Советларының саны түбәндәге таблицада күрсәтелә.

Союзный республикаларның исемнәре	Край советлары	Өлкә советлары	Округ советлары	Район советлары	Шәһәр советлары	Шәһәрләрдә район советлары	Авыл һәм поселкы советлары
РСФСР	6	41	20	2.311	578	268	41.797
Украина ССР	—	15	—	526	153	59	11.327
Белоруссия ССР	—	5	—	94	35	3	1.453
Азербайҗан ССР	—	1	—	66	25	19	1.165
Грузия ССР	—	1	—	68	28	7	1.121
Әрмәнстан ССР	—	—	—	38	9	4	684
Төркмәнстан ССР	—	5	—	48	12	3	474
Үзбәкстан ССР	—	5	1	116	25	9	1.420
Тажикстан ССР	—	5	—	66	7	3	485
Казагыстан ССР	—	14	—	192	31	11	2.696
Кыргызстан ССР	—	5	—	47	9	3	561

Хезмәт ияләре депутатларының край, өлкә, округ, район, шәһәр, авыл һәм поселкы Советларына сайлаулар бер үк вакытта гомуми сайлау участкыларында һәм барлык җирле Советларга сайлаулар өчен гомуми булган сайлаучылар исемлекләре буенча үткәрелделәр.

Сайлаучылар исемлекләрендә барлыгы 93.547.797 сайлаучы теркәлде, шулардан тавыш бирүдә 92.812.237 кеше катнашты. Бу—сайлаучыларның гомуми санының 99,21 проценты.

Аерым союзный республикалар буенча алганда, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларда тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның саны түбәндәге таблицада күрсәтелгән.

Союзный республикаларның исемнәре	Сайлаучылар саны	Тавыш бирүчеләр саны	Процентлар белән
РСФСР	59.852.283	59.367.524	99,19
Украина ССР	17.608.993	17.496.335	99,36
Белоруссия ССР	2.908.797	2.887.219	99,26
Азербайҗан ССР	1.601.538	1.592.432	99,43
Грузия ССР	1.936.799	1.926.985	99,49
Әрмәнстан ССР	621.095	615.263	99,06
Төркмәнстан ССР	705.215	701.235	99,44
Үзбәкстан ССР	3.615.695	3.560.966	98,49
Тажикстан ССР	815.979	810.170	99,29
Казагыстан ССР	3.075.914	3.056.661	99,37
Кыргызстан ССР	805.489	797.447	99,00

Тавыш бирүнең нәтиҗәләре күрсәткәнчә, сайлаучылар коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен бердәм рәвештә тавыш биргәннәр. Сайланган депутатлар барсы да—коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары.

Хезмәт ияләре депутатларының өлкә, район, шәһәр, авыл һәм поселкы Советларына сайлауларда коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен тавыш биргән сайлаучыларның саны һәм тавыш бирүдә катнашучылар санына карата аларның проценты аерым Союзный республикаларга бүленеп түбәндәге таблицада күрсәтелгән:

Союзный республикаларның исемнәре	Өлкә советлары	Район советлары	Шәһәр советлары	Шәһәрләрдә райсоветлар	Авыл һәм поселкы советлары
РСФСР	45.300.747	40.692.985	20.177.609	12.129.471	37.219.932
процентлар белән	98,97	98,56	97,99	97,98	97,77
Украина ССР	16.970.137	12.179.175	6.035.703	3.086.574	11.275.960
процентлар белән	99,03	98,69	97,95	98,04	98,07
Белоруссия ССР	2.852.658	2.221.722	707.585	136.597	2.054.718
процентлар белән	98,80	98,21	98,31	98,70	96,96
Азербайҗан ССР	69.122	1.039.329	632.603	522.981	1.053.821
процентлар белән	99,62	99,50	98,33	98,15	99,23
Грузия ССР	49.200	1.451.532	601.592	318.267	1.336.985
процентлар белән	99,43	99,64	99,15	98,86	99,40
Әрмәнстан ССР	—	469.058	170.206	105.538	422.877
процентлар белән	—	98,76	98,66	98,63	98,26
Төркмәнстан ССР	696.528	502.102	205.785	80.348	498.843
процентлар белән	99,33	99,72	98,19	97,84	99,63
Үзбәкстан ССР	3.267.933	2.740.520	788.767	419.562	2.735.151
процентлар белән	99,39	99,59	98,28	98,31	99,47
Тажикстан ССР	806.274	689.116	120.232	64.228	687.769
процентлар белән	99,52	99,69	98,05	96,73	99,60
Казагыстан ССР	3.039.159	2.371.520	742.960	270.219	2.310.822
процентлар белән	99,43	99,48	98,34	98,64	99,23
Кыргызстан ССР	791.507	663.303	128.958	58.160	657.312
процентлар белән	99,26	99,13	97,53	97,65	98,92
СССР буенча барлыгы	73.843.265	65.020.362	30.312.000	17.191.945	60.254.190
процентлар белән	99,02	98,72	98,04	98,03	98,04

Барлык җирле Советларга барлыгы 1.281.008 кеше сайланды. Сайланган депутатлар арасында хатын-кызлар—422.279 кеше (32,96 процент), ВКП(б) членнары һәм кандидатлары 402.398 кеше (31,41 процент) һәм партиясезләр 878.610 кеше (68,59 процент).

Аерым союзный республикалар буенча барлык сайланган депутатларның составы түбәндәге таблицада күрсәтелгән.

Союзный республикаларның исемнәре	Сайланган депутатлар барлыгы	Шул исәптән: Хатын-кызлар		ВКП(б) членнары һәм кандидатлары		Партиясезләр	
		Абсолют сан	Процентлар	Абсолют сан	Процентлар	Абсолют сан	Процентлар
РСФСР	817.187	269.213	32,94	47.589	30,30	569.598	69,70
Украина ССР	231.728	76.150	32,86	74.744	32,26	156.984	67,74
Белоруссия ССР	40.391	12.653	31,33	9.942	24,61	30.449	75,39
Азербайҗан ССР	26.057	8.943	34,32	10.363	39,77	15.694	60,23
Грузия ССР	28.358	9.910	34,95	11.383	40,14	16.975	59,85
Әрмәнстан ССР	11.984	3.753	31,32	5.577	46,54	6.407	53,46
Төркмәнстан ССР	10.581	3.619	34,20	3.355	31,71	7.226	68,29
Үзбәкстан ССР	40.765	13.853	33,98	13.154	32,27	27.611	67,73
Тажикстан ССР	12.658	4.173	32,97	3.274	25,87	9.384	74,13
Казагыстан ССР	48.762	15.880	32,57	19.253	39,48	29.509	60,52
Кыргызстан ССР	12.537	4.132	32,96	3.764	30,02	8.773	69,98

134 округ буенча хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр, авыл һәм поселкы советларына депутатлар сайланмаган. 125 округта тавышка куелган кандидатлар тавышларның абсолют күпчелеген алмаганнар. 6 округта теркәлгән кандидатлар үлү аркасында сайлаулар булмаган һәм 3 округта кар бураннары аркасында сайлаучыларның күпчелеге килмәгәнлектән, сайлаулар булмаган. „Сайлаулар турындагы положение“гә туры китереп, бу округларның барсында да яңа сайлаулар билгеләнә.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КРАЙ СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Край күләмендәге сайлау комиссияләре биргән саннарга караганда, депутатлар сайлау хезмәт ияләре депутатларының 6 край советының барсына да үткәрелгән. Сайлаулар 649 сайлау округының барсында да булган. Сайлаучыларның гомуми санынннан—7.268.357 кешедән тавыш бирүдә 7.216.888 кеше, яки 99,29 процент катнашкан.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 7.161.668 кеше, яки тавыш бирүдә катнашучыларның гомуми санының 99,23 проценты тавыш биргән.

„РСФСР хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы положение“ нең 110 нчы статьясе нигезендә дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—2.436. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—52.784.

Хезмәт ияләре депутатларының край Советларына барлыгы 649 депутат сайланган. Сайланган депутатлар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары. Хезмәт ияләре депутатларының край Советларына сайланган депутатлар арасында 158 хатын-кыз бар—24,35 процент. ВКП(б) членнары һәм кандидатлары 469 кеше—72,27 процент һәм партиясезләр 180 кеше—27,73 процент.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ӨЛКӘ СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Өлкә күләмендәге сайлау комиссияләре биргән саннарга караганда, депутатлар сайлау хезмәт ияләре депутатларының 97 өлкә советының барсында да үткәрелгән. Сайлаулар 7.867 сайлау округының барсында да булган. Сайлаучыларның гомуми санынннан—75.074.869 кешедән тавыш бирүдә 74.570.896 кеше, яки 99,33 процент катнашкан.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 73.843.265 кеше, яки тавыш бирүдә катнашучыларның гомуми санының 99,02 проценты тавыш биргән.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы положениеләрнең тиешле статьяләре нигезендә дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—43.859. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—683.772.

Хезмәт ияләре депутатларының өлкә Советларына барлыгы 7.867 депутат сайланган. Сайланган депутатлар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары. Хезмәт ияләре депутатларының өлкә Советларына сайланган депутатлар арасында 2.254 хатын-кыз бар—28,65 процент. ВКП(б) членнары һәм кандидатлары 5.531 кеше—70,31 процент һәм партиясезләр 2.336 кеше—29,69 процент.

Аерым Союзный республикалар буенча өлкә Советларына сайланган депутатларның составы түбәндәге таблицада күрсәтелә.

Союзный республикаларның исемнәре	Сайланган депутатлар барлыгы	Шул исәптән: Хатын-кызлар		ВКП(б) членнары һәм кандидатлары		Партиясезләр	
		Абсолют сан	Процентлар	Абсолют сан	Процентлар	Абсолют сан	Процентлар
РСФСР	3.748	1.043	27,83	2.648	70,65	1.100	29,35
Украина ССР	1.341	380	28,34	935	69,72	406	30,28
Белоруссия ССР	390	119	30,51	274	70,26	116	29,74
Азербайҗан ССР	63	19	30,16	45	71,43	18	28,57
Грузия ССР	56	20	35,71	40	71,43	16	28,57
Төркмәнстан ССР	274	76	27,74	180	65,69	94	34,31
Үзбәкстан ССР	371	113	30,46	284	76,55	87	23,45
Тажикстан ССР	334	99	29,64	231	69,16	103	30,84
Казагыстан ССР	1.007	311	30,88	686	68,12	321	31,88
Кыргызстан ССР	283	74	26,15	208	73,50	75	26,50

Әрмәнстан ССР өлкәләргә бүленми.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ОКРУГ СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Округ (милли һәм административ округ) күләмендәге сайлау комиссияләре биргән саннарга караганда, депутатлар сайлау хезмәт ияләре депутатларының 21 округ Советының барсына да үткәрелгән. Сайлаулар 944 сайлау округының барсында да булган. Сайлаучыларның гомуми санынннан—1.791.494 кешедән тавыш бирүдә 1.768.949 кеше, яки 98,74 процент катнашкан.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 1.749.523 кеше, яки тавыш бирүдә катнашучыларның гомуми санының 98,90 проценты тавыш биргән.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы положениеләрнең тиешле статьяләре нигезендә дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—1.642. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—17.784.

Хезмәт ияләре депутатларының округ советларына барлыгы 944 депутат сайланган. Сайланган депутатлар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары. Хезмәт ияләре депутатларының округ Советларына сайланган депутатлар арасында хатын-кызлар 266 кеше—28,18 процент. ВКП(б) членнары һәм кандидатлары 623 кеше—66,00 процент, партиясезләр 321 кеше—34,00 процент.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Район күләмендәге сайлау комиссияләре биргән саннарга караганда, депутатлар сайлау хезмәт ияләре депутатларының 3.572 район Советының барсына да үткәрелгән. Сайлаулар 130.145 сайлау округының 130.143 ндә булган. Сайлаучыларның гомуми санынннан—66.386.221 кешедән тавыш бирүдә 65.864.845 кеше, яки 99,21 процент катнашкан.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 65.020.362 кеше, яки тавыш бирүдә катнашучыларның гомуми санының 98,72 проценты тавыш биргән.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы положениеләрнең тиешле статьяләре нигезендә дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—45.588. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—798.895.

Хезмәт ияләре депутатларының район Советларына барлыгы 130.139 кеше сайланган. Сайланган депутатлар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары. Хезмәт ияләре депутатларының район Советларына сайланган депутатлар арасында хатын-кызлар 42.049 кеше—32,31 процент. ВКП(б) членнары һәм кандидатлары 79.672 кеше—61,22 процент һәм партиясезләр 50.467 кеше—38,78 процент.

Аерым Союзный республикалар буенча район Советларына сайланган депутатларның составы түбәндәге таблицада күрсәтелгән.

Союзный республикаларның исемнәре	Сайланган депутатлар барлыгы	Шул исәптән: Хатын-кызлар		ВКП(б) членнары һәм кандидатлары		Партиясезләр	
		Абсолют сан	Процентлар	Абсолют сан	Процентлар	Абсолют сан	Процентлар
РСФСР	82.271	26.629	32,37	50.833	61,79	31.438	38,21
Украина ССР	21.757	7.272	33,42	13.545	62,25	8.212	37,75
Белоруссия ССР	4.271	1.419	33,22	2.603	60,95	1.668	39,05
Азербайҗан ССР	2.355	750	31,85	1.389	58,98	966	41,02
Грузия ССР	3.510	924	26,32	1.703	48,52	1.807	51,48
Әрмәнстан ССР	1.161	353	30,40	756	65,12	405	34,88
Төркмәнстан ССР	1.273	418	32,84	722	56,72	551	43,28
Үзбәкстан ССР	4.811	1.562	32,47	2.833	58,89	1.978	41,11
Тажикстан ССР	1.802	519	28,80	1.045	57,99	757	42,01
Казагыстан ССР	5.483	1.777	32,41	3.353	61,15	2.130	38,85
Кыргызстан ССР	1.445	426	29,48	890	61,59	555	38,41

4 сайлау округында тавышка куелган кандидатлар тавышларның абсолют күпчелеген алмадылар. Теркәлгән кандидатларның үлүләре аркасында 2 сайлау округында сайлаулар булмады. Сайлаулар турындагы положениегә туры китереп бу округларда яңа сайлаулар билгеләнә.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ШӘҺӘР СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Шәһәр күләмендәге сайлау комиссияләре биргән саннарга караганда, хезмәт ияләре депутатларының 912 шәһәр Советының барсына да депутатлар сайлау үткәрелгән. 96.916 сайлау округының барсында да сайлаулар булган. Сайлаучыларның гомуми санынннан—31.152.792 кешедән тавыш бирүдә 30.917.437 кеше, яки 99,24 процент катнашкан.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 30.312.000 кеше, яки тавыш бирүдә катнашучыларның гомуми санының 98,04 проценты тавыш биргән.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы положениеләрнең тиешле статьяләре нигезендә дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—30.262. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—575.175.

Хезмәт ияләре депутатларының шәһәр Советларына барлыгы 96.915 депутат сайланган. Сайланган депутатлар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары. Хезмәт ияләре депутатларының шәһәр Советларына сайланган депутатлар арасында хатын-кызлар—36.268—37,42 процент. ВКП(б) членнары һәм кандидатлары—49.198 кеше—50,76 процент һәм партиясезләр 47.717 кеше—49,24 процент.

Аерым союзный республикалар буенча шәһәр Советларына сайланган депутатларның составы түбәндәге таблицада күрсәтелгән.

Союзный республикаларның исемнәре	Сайланган депутатлар барлыгы	Шул исәптән: Хатын-кызлар		ВКП(б) членнары һәм кандидатлары		Партиясезләр	
		Абсолют сан	Процентлар белән	Абсолют сан	Процентлар белән	Абсолют сан	Процентлар белән
РСФСР	61.567	23.347	37,92	31.151	50,60	30.416	49,40
Украина ССР	19.420	7.191	37,03	9.912	51,04	9.508	48,96
Белоруссия ССР	2.997	1.073	35,80	1.509	50,35	1.488	49,65
Азербайҗан ССР	1.948	737	37,83	959	49,23	989	50,77
Грузия ССР	2.005	750	37,41	1.006	50,17	999	49,83
Әрмәнстан ССР	741	266	35,90	378	51,01	363	48,99
Төркмәнстан ССР	919	356	38,74	475	51,69	444	48,31
Үзбәкстан ССР	2.759	992	35,96	1.443	52,30	1.316	47,70
Тажикстан ССР	567	195	34,39	321	56,61	246	43,39
Казагыстан ССР	3.343	1.136	33,98	1.712	51,21	1.631	43,79
Кыргызстан ССР	649	225	34,67	332	51,16	317	48,84

1 сайлау округында тавышка куелган кандидат тавышларның абсолют күпчелеген алмаган. Сайлаулар турындагы положениегә туры китереп бу округта яңа сайлаулар билгеләнә.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ШӘҺӘРЛӘРДӘГЕ РАЙОН СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Районнар күләмендәге сайлау комиссияләре биргән саннарга караганда, сайлаулар хезмәт ияләре депутатларының 389 район Советының барсына да үткәрелгән. Сайлаулар 46.200 сайлау округының барсында да булган. Сайлаучыларның гомуми санынннан—17.646.589 кешедән тавыш бирүдә 17.536.598 кеше, яки 99,38 процент катнашкан.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 17.191.945 кеше, яки тавыш бирүдә катнашучыларның гомуми санының 98,03 проценты тавыш биргән.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы положениеләренең тиешле статьяләре нигезендә дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—16.486. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—328.167.

Хезмәт ияләре депутатларының район Советларына барлыгы 46.199 депутат сайланган. Сайланган депутатлар барсы да—коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары. Хезмәт ияләре депутатларының район Советларына сайланган депутатлар арасында хатын-кызлар—18.142—39,27 процент. ВКП(б) членнары һәм кандидатлары—22.573 кеше—48,86 процент һәм партиясезләр—23.626 кеше—51,14 процент.

Аерым Союзный республикалар буенча шәһәрләрдәге райсоветларга сайланган депутатларның составы түбәндәге таблицада күрсәтелгән.

Союзный республикаларның исемнәре	Сайланган депутатлар барлыгы	Шул исәптән: Хатын-кызлар		ВКП(б) членнары һәм кандидатлары		Партиясезләр	
		Абсолют сан	Процентлар белән	Абсолют сан	Процентлар белән	Абсолют сан	Процентлар белән
РСФСР	30.736	12.255	39,87	14.969	48,70	15.767	51,30
Украина ССР	8.833	3.405	38,55	4.319	48,90	4.514	51,10
Белоруссия ССР	420	169	40,24	215	51,19	205	48,81
Азербайҗан ССР	1.910	698	36,54	946	49,53	964	50,47
Грузия ССР	1.035	376	36,33	509	49,18	526	50,82
Әрмәнстан ССР	356	135	37,92	166	46,63	190	53,37
Төркмәнстан ССР	254	93	36,61	130	51,18	124	48,82
Үзбәкстан ССР	1.427	544	38,12	711	49,82	716	50,18
Тажикстан ССР	172	66	38,37	80	46,51	92	53,49
Казагыстан ССР	872	319	36,58	438	50,23	434	49,77
Кыргызстан ССР	184	82	44,57	90	48,91	94	51,09

1 сайлау округында тавышка куелган кандидат тавышларның абсолют күпчелеген алмаган. Сайлаулар турындагы положениегә туры китереп бу округта яңа сайлаулар билгеләнә.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ АВЫЛ ҺӘМ ПОСЕЛКЫ СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Авыл һәм поселкы күләмендәге сайлау комиссияләре биргән саннарга караганда, сайлаулар хезмәт ияләре депутатларының 63.183 авыл һәм поселкы Советының барсына да үткәрелгән. Сайлаулар 998.421 сайлау округының 998.414 ендә булган. Сайлаучыларның гомуми санынннан—61.936.333 кешедән тавыш бирүдә 61.457.922 кеше, яки 99,23 процент катнашкан.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 60.254.190 кеше, яки тавыш бирүдә катнашучыларның гомуми санының 98,04 проценты тавыш биргән.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы положениеләрнең тиешле статьяләре нигезендә дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—67.753. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—1.135.979.

Хезмәт ияләре депутатларының авыл һәм поселкы Советларына барлыгы 998.295 депутат сайланган. Сайланган депутатлар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары. Хезмәт ияләре депутатларының авыл һәм поселкы Советларына сайланган депутатлар арасында хатын-кызлар—323.142 кеше—32,37 процент. ВКП(б) членнары һәм кандидатлары—244.332 кеше—24,47 процент, партиясезләр—753.963 кеше—75,53 процент.

Аерым Союзный республикалар буенча хезмәт ияләре депутатларының авыл һәм поселкы Советларына сайланган депутатларның составы түбәндәге таблицада күрсәтелгән.

Союзный республикаларның исемнәре	Сайланган депутатлар барлыгы	Шул исәптән: Хатын-кызлар		ВКП(б) членнары һәм кандидатлары		Партиясезләр	
		Абсолют сан	Процентлар белән	Абсолют сан	Процентлар белән	Абсолют сан	Процентлар белән
РСФСР	637.325	205.533	32,25	146.930	23,05	490.395	76,95
Украина ССР	180.377	57.902	32,10	46.033	25,52	134.344	74,48
Белоруссия ССР	32.313	9.873	30,55	5.341	16,53	26.972	83,47
Азербайҗан ССР	19.781	6.739	34,07	7.024	35,51	12.757	64,49
Грузия ССР	21.752	7.840	36,04	8.125	37,35	13.627	62,65
Әрмәнстан ССР	9.726	2.999	30,83	4.277	43,97	5.449	56,03
Төркмәнстан ССР	7.861	2.676	34,04	1.848	23,51	6.013	76,49
Үзбәкстан ССР	31.344	10.624	33,89	7.849	25,04	23.495	74,96
Тажикстан ССР	9.783	3.294	33,67	1.597	16,32	8.186	83,68
Казагыстан ССР	38.057	12.337	32,42	13.064	34,33	24.993	65,67
Кыргызстан ССР	9.976	3.325	33,33	2.244	22,49	7.732	77,51

119 сайлау округында тавышка куелган кандидатлар тавышларның абсолют күпчелеген алмаганнар. Теркәлгән кандидатларның үлүе аркасында 4 сайлау округында һәм кар бураны аркасында сайлаучыларның күпчелеге сайлауларга килмәгәнлектән 3 округта сайлаулар булмаган. Сайлаулар турындагы положениеләргә туры китереп бу округларда яңа сайлаулар билгеләнә.

Хезмәт ияләре депутатларының Кукмара район Советының беренче сессиясе

ДЕПУТАТ ДИГӘН МАКТАУЛЫ ИСЕМНЕ НАМУС БЕЛӘН АКЛАРБЫЗ

Карт депутат иптәш Х. Г. Газизуллиннең сессияне ачканда сөйләгән речь

Депутат иптәшләр! Миңа Кукмара поселкысының карт эшчесенә, арагыздагы карт депутатка хезмәт ияләре дипутатларының район Советының беренче сессиясен ачу бәхете төште. Бу мине чиксез шатландыра һәм сезне беренче сессиябез белән котлыйм.

Иптәшләр! Район хезмәт ияләре безне дәүләт властының район Советына депутат итеп сайлап, безгә бөек ышаныч белдерделәр һәм зур ихтирам күрсәттеләр. Халкыбызның бу ышанычын тулы аклау өчен без армый-талмый эшләргә тиешбез. Депутатлык бурычын намуслы рәвештә үтәүдән дә зур бәхет булу мөмкин түгел. Һәм бу бурычны без бөек юлбашчыбыз, сөекле атабыз иптәш Сталин өйрәткәнчә башкарырбыз.

Депутат иптәшләр! Элекке авыр тормышны мин үз җилкәмдә нык татыдым. Миңа хәзер 56 яшь. Шуның 34 елын авыр, ләгънәтле, караңгы тормышта үткәрдем. Ачлык, мохтаҗлык буа иде.

Ә хәзер! Хәзер минем тормышым бөтенләй башкача. Бүгенге сессияне ачу факты үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Әйе, без илебезнең тулы хокуклы хуҗалары. Сайлый да, сайлана да алабыз.

Фабрикабыз танымаслык булып үзгәрде. Ул хәзер бай техникага ия һәм аның менә дигән кадрлары, мактаулы кешеләре бар. Хезмәт шартлары әйтеп бетергесез дәрәҗәдә җиңеләйделәр. Стахановча эшләү өчен барлык шартлар тудырылган.

Депутат иптәшләр! Без капиталистик чолганышта яшибез. Моны без бер генә минутка да онытмыйбыз. Илебезнең оборона һәм экономик куәтен ныгыту өчен намус белән эшләү мактаулы бурычыбыз һәм бу бурычны без большевикларча үтибез. Сугыш теләмибез, ләкин дошман һөҗүм итә икән, ул үз җирендә тар-мар ителер. Бөек Ватаныбыз тынычлыгын күкрәк киереп сакларбыз.

Иптәшләр! Безгә, дәүләтнең җирле властьы органнарына сайланган депутатларга, күп төрле җидди һәм җаваплы эшләр йөкләнә. Большевиклар бер кайчан да җаваплылыктан һәм кыенлыктан курыкмыйлар. Без, депутатлар, халкыбызның тормыш, көнкүреш шартларының тагын да яхшыруы өчен, илебез тагын да куәтлерәк булсын өчен зур энергия белән эшләргә тиешбез. Һәрбер депутатның бурычы — үзенең сайлаучылары тапшырган ышанычны намус белән аклау.

Депутат иптәшләр! Без, депутатлар, халык хезмәтчеләре икәнлегебезне бер кайчан да онытмаска тиешбез. Сайлаучыларыбызның наказларын үтәүдә без һәр вакыт бөек Ленин, бөек Сталин күрсәтмәләреннән чыгып эш итәргә тиешбез.

Яшәсен безнең туган, бөек большевиклар партиясе! (Алкышлар).

Яшәсен Советлар властьы! (Алкышлар).

Яшәсен безнең юлбашчыбыз, бөек остазыбыз һәм туганыбыз иптәш Сталин! (Озакка сузылган көчле кул чабулар).

Депутат иптәшләр! Хезмәт ияләре депутатларының Кукмара район Советының беренче сессиясен ачык дип иглан итәм. (Алкышлар).

РӘСЕМДӘ: Кукмара район Советының орденлы депутатлары (сулдан уңга): Хәсәнев, Хәмидуллин, Мортазин һәм Галиев иптәшләр. Басыров фотосы.

АЛДЫНГЫЛЫКНЫ НЫГЫТЫРБЫЗ

(Сессия ачылу хөрмәтенә багышланып, Кукмара поселкысында үткәрелгән митингта „Электро" колхозы делегациясе исеменнән чыгып сөйләүче комсомолец иптәш Хисамиев речьненнән).

— Депутат иптәшләр! Сезгә, районыбызның атаклы кешеләренә, халкыбыз депутатларына „Электро" колхозы членнарыннан большевистик кайнар сәлам тапшырам **(кул чабулар).**

Депутат иптәшләр! Советларның җирле органнарына сайлаулар кампаниясе массаның политик һәм производство активлыгын моңа кадәр күрелмәгән дәрәҗәдә югары күтәрде. 24 нче декабрь көнне илебезнең барлык хезмәт ияләре дә бәйрәмчә каршылап, яңа җиңүләр белән билгеләп үттеләр.

Хәзер без барлык игътибарны сайлаулар кампаниясендә күтәрелгән активлыкны ныгытуга, социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтенең тагын да киңрәк колач алуына юнәлттек. Социалистик ярыш язгы чәчүгә хәзерлек эшендә көчле этәргеч ясады. Колхозыбызның мактаулы кешеләре—стахановчылар яңа уңышлар яулап алалар.

Хезмәт ияләре депутатларының район Советының беренче сессиясен колхозыбыз зур гына казанышлар белән каршылады. Һава шартларының коры булуына карамастан, без, 1939 нчы елда, агротехника чараларын дөрес куллану нәтиҗәсендә, 1938 нче елга караганда, ашлыкны һәр гектардан 3 центнер артык алуга ирештек. Дәүләт алдындагы йөкләмәләребезне тулысы белән үтәдек.

Гектарыннан 100 пот ашлык алу турында Калинин районы колхозчылары чакыруына без бердәм рәвештә кушылдык. Язгы чәчүгә хәзерлектә социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдердек. Бу өлкәдә байтак кына эшләр башкарылды инде.

Мәсәлән, чәчү өчен орлык чистарту эшен тәгәлләдек. 265 гектар җирдә кар тоту үткәрдек. Чәчүлек кырларына 1.240 тонна тирес чыгардык, 11 тонна көл җинадык. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонтны шушы көннәрдә тәгәллибез. Агротехника түгәрәкләрендә 110 кеше укый. Быел югары иген уңышы алуга ирешү өчен ике ефремовчы звено төзибез. Язгы чәчүне кыска срокта, югары сыйфатлы итеп үткәрү өчен барлык чараларны күрәчәкбез.

Безнең колхоз районда иң зур һәм алдынгы колхозларның берсе. 1940 нчы елда тагын да зуррак уңышлар яулап алырбыз.

Яшәсен бөек Ленин — Сталин партиясе! (Кул чабулар)

Хезмәт ияләре депутатлары Советының Кукмара районы башкарма комитеты составы. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): беренче рәттә—башкарма комитет председателе Нигматуллин, председатель урынбасары Рахматуллин, секретарь Большов һәм членнар—Шулдеев; икенче рәттә—Шәрипова, Карпов, Хәмидуллин, Могинова һәм Мехәммәтҗанов иптәшләр. Басыров фотосы.

ЗУР АКТИВЛЫК ҺӘМ БЕРДӘМЛЕК

*Мандат комиссиясе председателе депутат Н. М. Мөбаракшин доклады *)*

Депутат иптәшләр!

Хезмәт ияләре депутатларының Кукмара Район Советына сайлаулар сайлаучыларның зур активлыгы һәм бердәмлеге белән үтте. Район Советына сайлауларда райондагы барлык 25.737 сайлаучыдан 25.247 кеше катнашты. Бу, сайлаучыларның гомуми санының 98 процентын тәшкил итә. Тавыш бирүдә катнашкан барлык сайлаучыларның 97,9 проценты коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына тавыш бирделәр һәм шуның белән алар партиябез һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тирәсенә нык тупланганлыкларын тагын да бер тапкыр күрсәттеләр. **(Көчле кул чабулар).** 1939 нчы елның 24 нче декабре—хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар көне—халкыбызның мораль—политик бердәмлегенең тагын бер ачык күрсәткече булды.

Мандат комиссиясе барлык материалларны тикшергәннән соң түбәндәгеләрне билгеләде: Район Советына депутатлыкка күрсәтелгән барлык кандидатлар да ТАССР Конституциясе нигезендә һәм җирле Советларга сайлаулар турындагы Положение нигезендә һәм аларга тулысынча туры китерелеп сайланган.

Бөек Сталинга, большевиклар партиясенә һәм Ватаныбызга чиксез мәхәббәт белән тулган, иптәш Сталин кайгыртучанлыгында тәрбияләнгән хезмәт ияләре район Советына депутатлар итеп үзләренең иң яхшы вәкилләрен сайладылар. Район Советына сайланган 51 депутатның 29 ы ВКП(б) членнары һәм кандидатлары, 4 се ВЛКСМ членнары, 18 е партиясезләр. Бу, хезмәт ияләре тарафыннан безнең данлыклы партиябезгә булган гаять зур ышанычны күрсәтә.

Район Советы депутатлары арасында социалистик промышленность һәм авыл хуҗалыгы стахановчылары, хезмәтнең эшләп чыгарышын югары күтәрүчеләр, укытучылар, агрономнар, врачлар, тракторчылар һәм башкалар бар. Район Советы депутатлары арасында хөкүмәтебез тарафыннан орден белән бүләкләнгән 3 кеше һәм медаль белән бүләкләнгән 1 кеше бар.

Безнең коммунистлар партиясе белән хөкүмәтебез совет яшьләре өчен бәхетле һәм шатлыклы тормыш тудырды. Алар дәүләтне идарә итү эшендә, барлык хезмәт ияләре шикелле үк, актив катнашалар. Безнең район Советына гына да 25 яштән түбән булган 10 кеше депутат булып сайланды. Депутатлар арасында хатын-кызлар 17 кеше. Болар совет хатын-кызларының иң алдынгы вәкилләре һәм бөек Сталинның аталарча кайгыртучанлык күрсәтүе белән тәрбияләнеп үскән кешеләр.

Совет халкы үзенең депутатлары итеп сайлап, безгә—район Советы депутатларына—гаять зур ышаныч күрсәтте. Сайлаучылар депутатларның нинди булырга тиешлекләре турында безгә Сталинчыл акыллы һәм сизгер наказлар бирделәр.

Иптәш Сталин Москва шәһәренең Сталинский сайлау округы сайлаучыларының сайлау алды җыелышында болай диде:

„Сайлаучылар, халык үзләренең депутатларыннан шуны таләп итәргә тиешләр ки, алар үз бурычлары югарылыгында торсыннар, алар үз эшләрендә политик обывательләр дәрәҗәсенә төшмәсеннәр, алар Ленин типындагы политик эшлеклеләр постында калсыннар, алар Ленин кебек үк, кем икәнлекләре ачык булган һәм билгеле булган эшлеклеләр булсыннар, алар Ленин кебек үк, сугышта куркусыз һәм халык дошманнарына карата рәхимсез булсыннар, алар, эш кыенлаша башлаганда һәм горизонтта нинди дә булса куркыныч гәүдәләнгәндә һәр төрле паникадан, паникага ошаган һәр төрле нәрсәдән азат булсыннар, алар, паникага ошаган һәр төрле нәрсәдән, Ленин кебек үк, азат булсыннар, алар, һәр яклап ориентация алу һәм барлык плюсларны һәм минусларны һәр яклап исәпкә алу кирәк булган катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә, Ленин кебек үк, бөек акыллы һәм ашыкмаучан булсыннар, алар, Ленин кебек үк, турылыклы һәм намуслы булсыннар, алар үз халкын, Ленин яраткан кебек үк, яратсыннар". (Көчле кул чабулар).

Без, барлык депутатлар да, иптәш Сталин күрсәтмәләрен тулысынча үтәргә һәм Ленин—Сталин типындагы эшлеклеләр булырга тиешбез. (Көчле кул чабулар).

Депутат иптәшләр!

Район Советы депутатларының полномочиеләрен тикшереп, мандат комиссиясе түбәндәге карарны кабул итте һәм аны район Советының беренче сиссиясе карамагына кертә:

1. Район Советына депутатлар сайлау 51 сайлау округының барсында да ТАССР Конституциясе һәм җирле Советларга сайлаулар турындагы Положение нигезендә һәм аларга тулысынча туры китерелеп үткәрелгән.

2. Нинди булса да сайлау округы буенча сайлауларны юкка чыгару өчен нигезләр юк, шулай ук район Советына депутатлар сайлаулар буенча Конституцияне һәм сайлаулар турындагы Положениене бозу турында сайлау округларында да һәм сайлау комиссияләрендә дә бер нинди дә жалобалар һәм заявлениеләр юк.

Югарыда әйтелгәннәр нигезендә мандат комиссиясе район күләмендәге сайлау комиссиясенә тергкәлгән барлык депутатларның полномочиеләрен дөрес дип таный. (Кул чабулар).

*) Кыскартылып алынды.

ХАЛЫК ТАНТАНАСЫ

Хезмәт ияләре депутатларының район Советының беренче сессиясе ачылу көнен Кукмара районы хезмәт ияләре шатлыклы бәйрәм — тантана итеп, зур уңышлар белән каршыладылар. Алар, Ленин — Сталин партиясе җитәкчелегендә, сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендә яулап алынган гаять зур казанышларыбыз белән рухланган хәлдә, бөек Ватаныбыз хөрмәтенә яңа җиңүләр бүләк иттеләр.

Илебезнең җиңүле рәвештә алга, коммунизмга барганлыгын Кукмара районы хезмәт ияләре үз районнары мисалендә дә ачык күрә алалар. Чыннан да, элек артта калган, караңгы Кукмара районы Совет властьы елларында танымаслык булып үзгәрде. Ул промышленность районы булып һәм бай техника белән коралланган эре авыл хуҗалыгы районы булып әверелде.

Мәсәлән, элек бояр Комаров биләгән киез итек фабрикасы хәзер, Сталинчыл бишьеллыклар чорында тамырыннан яңартылды, бай техника белән баетылды. Андагы эшчеләрнең саны 300 дән 1.300 кешегә җитте. „Кызыл Тукучы" фабрикасы элек бер ел буена эшләгән продукцияне, хәзер 2—3 көндә эшләп чыгара.

Шуның өстәвенә районда хәзер 12 промартель бар. Гомумән районның промышленность предприятиеләре 1939 нчы елда илгә 30 миллион сумлык продукция бирделәр.

Авыл хуҗалыгы аеруча кызу үсә. Хәзер районда 2 МТС бар. Колхозларга 101 трактор, 47 комбайн һәм башка шундый катлаулы эре машиналар хезмәт күрсәтәләр. Нәтиҗәдә, колхоз кырларының уңыш бирүе элеккегә караганда 2—3 тапкыр үсте. Терлекчелек өлкәсендә дә шундый ук үсешне күрәбез.

Формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культура чәчәк ата. Октябрь революциясенә кадәр үзенең наданлыгы һәм культурасызлыгы белән билгеле булган Кукмара районына хәзер карагыз! Монда хәзер урта, тулы булмаган урта һәм башлангыч мәктәпләрнең саны 81 гә, аларда укучы балалар саны 9.500 гә, укытучылар саны 336 га җитте. Районда хәзер 21 библиотика һәм 77 клуб, уку өйләре һәм башкалар бар. Халык мәгарифенә 1939 нчы ел бюджеты буенча гына да 3 миллион сумнан артык акча тотылды. Үсеш, 1934 нче ел белән чагыштырганда, 347 процент тәшкил итә. Халыкның сәламәтлеген саклау эшенә 1 миллион сумга якын акча тотылды.

***

4 нче гыйнвар иртәсе. ВКП(б) райкомының парткабинет бинасы матур итеп, бәйрәмчә бизәлгән.

Депутатлар—районның атаклы кешеләре парткабинет бинасына сәгать 4 тә үк җыелып беттеләр.

Депутатлар арасында без, граждannar сугышы елларында күрсәткән батырлыклары өчен „Кызыл Байрак" ордены белән бүләкләнгән Хәмидуллин, Мортазин иптәшләрне һәм районның алдынгы „Электро" колхозы председателе Әхәтев, Яниль МТС ының мактаулы тракторчысы Гайнуллина, дәүләт алдындагы йөкләмәләрен вакытыннан элек үтәүче Яниль авыл советы председателе Хисмәтев, Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Шәрипова, хөкүмәтебез тарафыннан „Хезмәттәге батырлык өчен" медале белән бүләкләнгән яшь укытучы Галиев, „Кызыл Тукучы" фабрикасының карт эшчесе, мактаулы стахановчы Газизуллин һәм башка иптәшләрне күрәбез.

Сәгать 5. Депутатлар һәм кунаклар утырышлар залына керәләр. Депутат, ВКП(б) райкомының беренче секретаре иптәш Шулдиев трибунага күтәрелә. Ул, Кукмара район Советының беренче сессиясен ачуны карт депутат Хәмидулла иптәш Газизуллингә тапшыру тәкдимен кертә. Сессия, бу тәкдимне бер тавыштан кабул итә.

Сессия, иптәш Газизуллин речьннән соң, сессиянең утырышларын алып бару өчен председатель һәм секретарь сайлый. Председатель итеп Г. Н. Сизаев һәм секретарь итеп М. Г. Ягфаров иптәшләр бер тавыштан сайланалар.

Депутат иптәш Рахмәтуллин тәкдиме буенча, сессия эшенең регламенты билгеләнде.

Сессия, көн тәртибендә торган мәсьәләләрне тикшерүгә күчә. Депутат иптәш Галиев мандат комиссиясен биш кешелек составта сайлау тәкдимен кертә һәм кандидатуралар күрсәтә. Сессия, мандат комиссиясен түбәндәге составта сайлады: Н. М. Мөбаракшин (председатель) һәм членнар—М. М. Могинова, Р. Ә. Әскәров, С. Ш. Шакиров, Җ. А. Әхметова.

Шуннан соң трибунага „Кызыл Тукучы" фабрикасы делегациясе күтәрелә. Алар монда кызыл байраклар күтәреп, сессияне котларга килгәннәр. Сессия аларны көчле алкышлар белән каршылый.

— Депутат иптәшләр!—ди делегация җитәкчесе, фабком председателе иптәш Әхмәтҗанов—без, Советларның җирле органнарына сайлаулар кампаниясен производство планын арттырып үтәүгә ирешү өчен көрәш билгесе астында алып бардык. Социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирде. Моңа кадәр хөкем сөреп килгән артта калучылыкны бетердек. 1939 нчы елның соңгы 6 айлык планын 104 процент итеп үтәдек.

Зал, делегацияне алкышлар белән озата. Фабрика делегациясе тәбригеннән соң, сессияне алып баручы председатель иптәш Сизаев сессиянең беренче утырышын ябык дип иглан итә һәм депутатларны Кукмара поселкысы хезмәт ияләренең митингысына чакыра.

Сәгать 7. Поселкы хезмәт ияләре төркем-төркем булып район клубына агылдылар. Хезмәт ияләре депутатларының район Советының беренче сессиясе ачылу хөрмәтенә багышланып үткәрелгән бу митингта 400 дән артык кеше катнашты. „Электро" колхозы, 2 нче номерлы урта мәктәп һәм Осоавиахим оешмасы вәкилләре депутатларны кайнар рәвештә котлыйлар, аларны бөек депутатлык хезмәтләрен үтәүгә керешүләре белән тәбрик итәләр. Митинг гаять зур оешканлык һәм активлык белән үтте.

5 нче гыйнварда сессия үзенең эшен дәвам иттерде. Район Советының башкарма комитетын сайлау турындагы тәкдим белән депутат иптәш Сираев чыгыш ясады. Сессия, бер тавыштан түбәндәге депутатлар составында башкарма комитетын сайлады.

Г. С. Нигматуллин—председатель, Н. Р. Рахмәтуллин—председатель урынбасары, А. Г. Большов—секретарь, членнар—П. К. Шулдиев, Н. И. Карпов, М. Ш. Шәрипова, М. М. Могинова, Х. Х. Хәмидуллин һәм С. М. Мөхәммәтҗанов.

Район Советының бүлекләрен төзү һәм бүлекләрнең мөдирләрен раслау турындагы тәкдим белән депутат иптәш Нигматуллин чыга. Сессия, Советның түбәндәге бүлекләрен раслады: җир, халык мәгарифе, финанс, сәүдә, сәламәтлек саклау, социаль тәэминат, юл, гомуми бүлек, план комиссиясе, кадрлар секторы.

Җир бүлеге мөдире итеп Шакиров, халык мәгарифе—Базуков, финанс—Ягфаров, сәүдә—Хәмидуллин, сәламәтлек саклау—Бәдерттинова, социаль тәэминат—Ярмөхәмитов, юл эшләре—Богомолов, гомуми бүлек—Соловьев, план комиссиясе председателе итеп Рахмәтуллин, кадрлар секторы мөдире итеп Евсеев иптәшләр расландылар.

Даими комиссияләрнең составы турындагы мәсьәлә буенча депутатлардан Большов, Гиляев, Баграмов, Шәрипова, Николаева, Шакиров, Әскәрев иптәшләр чыгып сөйләделәр. Сессия бюджет, сәүдә, җирле промышленность, мәктәпләр, сәламәтлек саклау һәм төзекләндерү комиссияләрен һәм аларның составларын раслады. Бу комиссияләр составына барлыгы 40 депутат сайланды.

Аннары, сессия көн тәртибендәге 5 нче мәсьәләне—мандат комиссиясенең отчет докладын тыңлауга күчә. Мандат комиссиясе председателе иптәш Мөбаракшинның кыска, ләкин тирән эчтәлекле докладын депутатлар зур кызыксыну белән тыңлыйлар. Совет халкын җиңүләрдән-җиңүләргә алып баручы бөек Ленин—Сталин партиясе һәм иптәш Сталин хөрмәтенә алкышлар һәм тәбрик авазлары яңгырый.

Сессия, мандат комиссиясенең отчет докладын бер тавыштан раслады. Шуның белән хезмәт ияләре депутатларының Кукмара район Советының беренче сессиясе үзенең эшен тәмам итте.

Ким Биков.

Чит илләрдә

МАННЕРГЕЙМГА КЕМ ЯРДӘМ ИТӘ?

СТОКГОЛЬМ, 5 гыйнвар. (ТАСС). Ак финнәргә ярдәмгә „ирекleләр“ туплауны оештыручыларның бөтен көчәнүләренә дә карамастан, Маннергейм финляндиясенә ярдәм итәргә теләүчеләр аз табыла. „Ню даг“ газетасының белдерүенә караганда, ирекleләрне туплау буенча махсус бюроларда башлыча офецерлар язылалар. Бер эшче дә язылмаган, крестьяннәр дә ак финнәр ягында сугышудан баш тарталар. Ирекleләрне туплаучылар алдауның һәм көчләүнең сыналган чараларын кулланcалар да, алар Маннергеймга ярдәмгә ак гвардеецлардан гына торган кечкенә отряд кына җибәрә алдылар.

Палач Маннергеймга швед офицерлары, сәүдәгәрләр, рус ак гвардеецлары булышлык итәләр. 1918 нче елны Финләндиягә ак гвардеецлар походының „ветераны“ Швеция генерал-майоры Линдер—алар арасында иң зур фигура. Тампердагы эшчеләр хәрәкәтен канлы рәвештә бастырганнан соң, Маннергеймның иң якын көрәштәше булган бу кеше фин армиясенең генерал — лейтенанты дәрәҗәсен алды. Хәзерге көндә шул ук Линдер яңадан ак Финләндиягә китте.

ФИН ЭШЧЕСЕНЕҢ ХАТЫ

СТОКГОЛЬМ, 4 гыйнвар. (ТАСС). „Ню даг“ газетасы кичә „Фин эшчесенең Швециядәге үз дустына хатын“ басып чыгарды. Фин эшчесе болай дип яза:

„Кадерле туганым! Маннергейм ак финнәрнең хәрби көчләренә командованиене кабул иткәннән соң аның тарафыннан иглан ителгән приказны укыгандырсың. Бу приказ ун меңнәрчә фин эшчеләренең күзләрен ачты. Ун меңнәрчә хезмәт ияләрен үтергән ак гвардеец офицерлар бандалары башлыгының — Маннергеймның приказын укыгач, без, карт кызыл гвардеецлар һәм Финләндиянең бөтен эшчеләр сыйныфы, нәрсә хис иткәнлекне син аңлыйсың. Хәзер дә сүз шул ук турыда бара.

Маннергеймчылар бандаларының терроры фин халкын азат итү өчен көрәшкә булган омтылышыбызны сындыра алмас. Монда ак финнәргә ярдәм итү өчен берничә йөз рус ак гвардеецлары килде“. Фин эшчесе үзенең хатын болай дип тәмам итә:

„Үзләренең киләчәкләре турында куркуга төшкән ак идарәчеләре Финләндиягә чит ил гаскәрләре килүне һәм аларның революцион хәрәкәтне бастыруларын телиләр. Син һәм синең швед иптәшләрең Финләндия эшчеләре һәм крестьяннәре көрәшә торган эшнең әһәмиятен ахрына кадәр аңларга тырышырсыз дип ышанам“.

БЕЛЬГИЯ КАБИНЕТЫНЫҢ ОТСТАВКАГА ЧЫГУЫ

ПАРИЖ, 5 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгының белдерүенә караганда, баш министр Пьерло җитәкчелегендәге Бельгия хөкүмәте отставкага чыккан. Король яңа кабинет төзүне яңадан Пьерлога тапшырган.

БЕЛЬГИЯДӘ ЯҢА ХӨКҮМӘТ

ПАРИЖ, 6 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Бельгиядә яңа хөкүмәт төзелгән. Пьерло элеккечә баш министр постын саклап калган. Спаак чит ил эшләре министре, Гутт финанс министре, генерал Дэни милли оборона министре булып калган. Вандерпортен эчке эшләр министре постын алган. Кабинет составына җәмагат эшләре министре постын алган бер генә яңа министр—Матань гына (сенатор, социалист) кергән. Тәэминат һәм информация министрлекләре бетерелгән.

Хөкүмәтнең яңа составында биш католик, дүрт социалист һәм ике либерал бар.

АМЕРИКА КОНГРЕССЫ СЕССИЯСЕНЕҢ АЧЫЛУЫ

ВАШИНГТОН, 4 гыйнвар. (ТАСС). Кичә Америка конгрессының сессиясе ачылды. Америка Кушма Штатлары президенты Рузвельт Америка Кушма Штатларының эчке һәм тышкы политикасы мәсьәләләренә багышланган хат белән конгресска мөрәҗәгать итте.

ИТАЛИЯДӘ КАРТОЧКА СИСТЕМАСЫ

БЕРЛИН, 5 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, якын көннәрдә туклану продуктларына карточка системасы кертеләчәге турында Римда рәсми рәвештә белдерү булган.

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 5 гыйнвар. (ТАСС). Кичә әйтерлек бер нәрсә дә булмаганлык турында рәсми рәвештә хәбәр ителә. Саар елгасыннан көнбатышка таба булган районда патрульләр арасында берничә бәрелеш булганлыгы гына әйтелә.

БЕРЛИН, 5 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәренә караганда, көнбатыш фронтта артиллериядән җиңелчә атышлар бара. Кайбер участкыларда артиллерия хәрәкәте җанлырак. Германия авиациясенең Англия һәм Франция өстендә разведка очышлары планлы рәвештә дәвам иткән.

Юнайтед пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 13 нче декабрьдә Германиянең „Адмирал граф Шпее“ исемле линкорына каршы сугышта катнашкан Англия крейсеры „Аякс“ Монтевидеога, ә „Ахиллес“ крейсеры—Буэнос - Айреска килеп җиткәннәр.

Лондоннан бирелгән өр яңа хәбәрләргә караганда, сугышның 17 атнасы эчендә Англия „контрабанда“ йөкләре дип атала торган йөкләрдән 537.600 тонна, Франция—429 мең тонна йөккә конфискация ясаганнар.

Антверпендагы (Бельгия) портның эшенә Европа сугышының һәлакәтле йогынты ясавы аркасында бу порт эшчеләренең хәле кискен рәвештә начарланган. 1938 нче елның октябрендә Антверпен портында 85.494 кеше эшләгән иде, ә үткән елның ноябрендә—27.181 генә кеше эшләде. (ТАСС).

Сугыш хәрәкәтләре турында Франция күзәтүе

БРЮССЕЛЬ, 6 гыйнвар. (ТАСС). „Журналь“ газетасының хәрби күзәтүендә болай диелә: „3 нче гыйнвар көне фронтта тыныч үтте, 4 нче гыйнварга каршы төн җанлырак булды. Патрульләр үзләренең гадәттәге бурычларын үтәделәр. Кечкә таба немецләр белән безнең гаскәрләр арасында бәрелеш булды. Немецләрнең һөҗүме кире кагылды. Немецләр, яраланучыларны үзләре белән алып, чигенделәр. Безнең гаскәрләр группасы патрульгә командалык иткән немец офицерының гәүдәсен алып кайтты. Авиация үзенең гадәттәге эшен эшләде. Англичаннар Германия базалары өстендә разведка очышлары ясадылар. Франция самолетлары фронт линияләре өстендә разведка очышлары ясадылар һәм кай чакларда дошман гаскәрләре урнашкан җирләргә тирән үтеп керделәр. Француз истребительләре эскадрильясе немец самолетлары белән сугышты. Сугыш нәтиҗәсез тәмам булды. Немецләр дә көнчыгыш Франция һәм Париж районы өстендә разведка очышлары ясадылар“.

Англиянең хәрби министре Хор-Белишаның һәм информация министре Макмилланның отставкага чыгулары

ЛОНДОН, 6 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, сугыш министре Хор-Белишаның һәм информация министре Макмилланның отставкага чыгулары турында бүген рәсми рәвештә хәбәр ителгән.

Король сугыш министре итеп Оливер Стэнлины, информация министре итеп Джон Рейтны һәм сәүдә министре итеп Эндрью Дунканны раслады.

Яхшы хәбардар булган даирәләрдә, Хор-Белишаның отставкага чыгуы сугышны алып бару мәсьәләләре буенча Англия кабинетында булган фикер каршылыклары аркасында килеп чыккан дип уйлыйлар.

***

Яңа сугыш министре Оливер Стэнли 1896 нчы елны туган. 1931 нче елдан 1933 нче елга кадәр ул эчке эшләр министренең парламент урынбасары булып эшләгән, 1933 нче елдан 1934 нче елга кадәр транспорт министре булган, 1934 нче елдан 1935 нче елга кадәр—хезмәт министре һәм 1935 нче елдан 1937 нче елга кадәр мәгариф министре постында эшләгән. 1937 нче елны Стэнли Чемберлен кабинетында сәүдә министрлегенә җитәкчелек иткән.

***

Джон Рейт-империя һава юллары компаниясенең („Империэл Эйруэйс“ ның) башлыгы.

***

Эндрью Дункан—Англия банкысы директорларының берсе һәм аңардан тыш Британия металлургия заводлары федерациясенең башкарма комитетына җитәкчелек итә.

ХОР-БЕЛИШАНЫҢ ОТСТАВКАГА ЧЫГУЫНА КАРАТА

ЛОНДОН, 6 гыйнвар. (ТАСС). Англия хөкүмәте составында үзгәрешләр булу уңае белән, Рейтер агентлыгы, Хор-Белишаның отставкага чыгуы Англиянең җәмагатчелек фикре өчен генә түгел, бәлки аның үзе өчен дә бөтенләй көтелмәгән хәл булды ди. Ышанычлы чыганаклардан алынган хәбәрләргә караганда, Хор-Белиша үзенең кичә Чемберлен белән булган сөйләшүенә кадәр Чемберленнең аңа хәрби министрлекне ташлап китәргә һәм сәүдә министре постын алырга такдим итәргә җыенуын уйламаган да. Шушы такдим уңае белән үзенең гаҗәпләнгәнлеген белдереп, Хор-Белиша аны кискен төстә кире какты. Монда Хор-Белишаның отставкага чыгуы аның Англиянең Франциядәге хәрби һава көчләренә җитәкчелек итүне Англия экспедиция армиясенең верховный командованиесенә тапшыру планы җимерелүнең нәтиҗәсе дип саныйлар. Сугыш башланганнан бирле Англия авиациясенең төп көчләре, Франциядә һәм Германиядә булган практикага каршы буларак, армиянең верховный командованиесенә бәйсез хәлдә иде.

Хор-Белиша шулай ук коры җир, хәрби диңгез һәм хәрби һава көчләренә җитәкчелек итүне бергә туплый алырлык оборона министрлеге төзү планын да яклагандыр дип уйлыйлар. Кабинетның бу планны кабул итүдән баш тартуы Хор-Белишаның отставкага чыгуын тизләткән.

Шул ук вакытта Лондонда Хор-Белиша Финләндиягә Англиядән сугыш материаллары җибәрүгә каршы чыккан дип раслыйлар.

Юкка чыгару.
В. Лисевич рәсме (ТАСС фото-клишесе).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Алынган хәбәрләргә караганда, кытай гаскәрләре Гуандун провинциясенең төньяк өлешендә япон позицияләренә һөҗүмне дәвам иттерәләр. Төп көчләр, дошманны куып барып, Кантон-Ханькоу тимер юлы буендагы Индэдән көньякта 30 километр алга киттеләр. Вэнь-Юаньнан көньякта кытай отрядлары авиация ярдәме белән территорияне япон гаскәрләреннән тазартуны дәвам иттерәләр.

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендәге фронтта соңгы көннәрдә кытай частьләре берничә әһәмиятле пунктны, шул исәптән Наньниннан 25 километр көнчыгышта Бумьяоны һәм Наньниннан 27 километр көньякта Учуньны алдылар.

КЫТАЙ АРМИЯСЕНЕҢ ЗУР УҢЫШЫ

ШАНХАЙ, 5 гыйнвар. (ТАСС). Кытайларның хәбәр итүләренә караганда, Гуандун провинциясендә японнарның яңа ел һөҗүме җимерелү белән төгәлләнгән. Бу һөҗүмнең төп бурычы Вэньюаньны (Гуандун провинциясенең төньяк өлешендә Кытай операцияләре базасы) алу, аннары кытайларның төп көчләренә флангыдан ударясау максады белән Шаочжоуга (Вэньюаньнан төньяктарак) бару иде.

1 һәм 2 нче гыйнварда Индэ — Вэньюань — Чаннин өчпочмагында зур сугышлар барган. Бу сугышлар нәтиҗәсендә гвардия дивизиясенең бер бригадасы тулысынча тар-мар ителгән. Япон гаскәрләренең калдыклары, тәртипсез рәвештә чигенеп, үлгән һәм яраланган 10.000 нән артык кешеләрен калдырып киткәннәр. Кытай гаскәрләре күп кенә пунктларны, шул исәптән Лянкоуны, шулай ук күп санда сугыш кирәк-яраклары кулга төшергәннәр.

Кантон — Ханькоу тимер юлында, Кантон белән Индэ арасындагы Бацзян районында 2 нче гыйнварда да зур сугыш булган. Бу сугышта японнарның 800 гә якын солдатлары үтерелгән. Шуннан соң японнар гомуми рәвештә чигенә башлаганнар.

КӨНБАТЫШ АНАТОЛИДА СУ БАСУ

ӘНКАРӘ, 5 гыйнвар. (ТАСС). Көнбатыш Анатолида көчле яңгырлар аркасында булган су басу Төркиянең халык хуҗалыгына зур зарар китерә. Су баскан районнардагы берничә елга һәм күлләр ярларыннан чыктылар. Эгей уйсулыгы тоташ диңгезгә әйләнде. Уннарча авыллар су астында калды. Бурса вилаятендә генә дә 366 йорт җимерелде, 300 йортны су агызды һәм 622 йорт су астында калды. Бурса районында 25 кеше, ә Камал Паша районында 50 кеше һәлак булды. Су басу Измир белән Әнкарә һәм башка пунктлар арасында тимер юл һәм телефон элемтәләрен өзде. Кырлар һәм чәчүлекләр су астында калганлыктан, крестьян халкы аеруча нык зарарланды.

Казанда укытучылар йортында, 5 нче һәм 16 нчы номерлы мәктәпләрдә укучы пионерлардан(сулдан)Ханов Сөләйман, Васильев Шура һәм Кира Гатовкиналар кул тигезлеге усяы буенча конусларга кольцолар киертеп уйныйлар.

И. Галиев фотосы.

УКУЧЫ БАЛАЛАРНЫҢ МОСКВАГА ЭКСКУРСИЯСЕ

Балаларның туризм һәм Экскурсияләр станциясе Югары класс укучыларының кышкы каникул вактында кызыл башкалага экскурсияләрен оештырды. Шушы көннәрдә 25 баладан торган бер группа Москвага китте.

Экскурсантлар Москвада Ленин мавзолеендә, Кызыл Армия һәм Сынлы Сәнгать музейләрендә булачаклар. Коммуналь хуҗалык музеендә оештырылган, Москваны реконструкцияләү турындагы күргәзмә белән танышачаклар һәм Союзлар Йортының Колонналы залына куелган елкада булачаклар.

КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ КОНЦЕРТ һӘМ ЭСТРАДА ЧЫГЫШЛАРЫ

Татарстан Дәүләт филармониясе, укучы балаларның каникуллары вактында, 25 кә якын концерт һәм эстрада чыгышлары үткәрүне планлаштырды.

3 нче гыйнварда Менжинский исемендәге клубта балалар өчен Бөтенсоюз концерт-гастрольләр берләшмәсенең, Татар Дәүләт Опера театры, радиокомитет һәм Татарстан Дәүләт филармониясе артистлары катнашы белән концерт бирелде. Концертта җыр, биү, художестволы сөйләү, гармон һәм башка номерлар белән Никола Глек, Фәйзи Юсупов, Гали Җәмлиханов, Госман Әлмиев, Гайшә Камаева, Зинаида һәм Петр Казаковлар һ. б. катнаштылар. Владимир Хронусов тантомарескалар театрын күрсәтте.

Каникул көннәрендә мәктәпләрдә, шулай ук мәктәп балалары һәм пионерлар йортында да концерт программасы белән кичәләр үткәрелә. Болардан тыш балаларның Моркваш, Зәңгәр Күл һәм Васильеводагы ял йортларына барып та концертлар биреләчәк

КАНИКУЛГА КҮҢЕЛЛЕ ПРЕМЬЕРА

Казандагы Яш Тамашачылар театрында Светловның „Әкиятләр“ дигән премьерасы зур уңыш белән бара. Театр коллективы бу премьераны укучы балаларның каникул көннәрендә күрсәтү өчен хәзерләде. Театр һәр көнне ике спектакль бирә. Балалар спектакльләргә зур кызыксыну белән йөриләр.

Каникул вактында 13 мең балага хезмәт күрсәтеләчәк.

КУРЧАК ТЕАТРЫНДА

Курчак театрының татар группасы балаларга „Шүрәле“ пьесасын күрсәтә башлады. Бу пьеса татар халык шагыйре Габдулла Тукай буенча эшләнгән.

Рус группасы „Рубин Гуд“ һәм „Чуртан кушуы буенча“ пьесаларын куя.

Курчак театры каникул көннәрендә мәктәпләрдә һәм клубларда бик күп санда кучмә постановкалар бирәчәк.

В. И. Ленин музей-йортында

Казандагы В. И. Ленин Музей-йорты капиталь ремонттан соң яңадан ачылып эшли башлады.

Владимир Ильичның абыйсы Дмитрий Ильич күрсәтүе буенча йортның бүлмәләрен яңадан дөресләп планлаштыру үткәрелде. Владимир Ильичның туганнан туган энесе Николай Иванович Веретенниковның күрсәтмәсе буенча бүлмәләргә махсус хәзерләнгән обойлар ябыштырылды. Обойларның үрнәкләре үткән йөзнең 80 нче елларындагы үрнәкләргә ошыйлар.

Владимир Ильичның бүлмәсенә Ленинның бабасыннан калган кара савыты куелды. Бу кара савыты музейгә Н. И. Веретенников тарафыннан бүләк ителде. Экспонатлар куелган зал кинәйтелде һәм өр яңадан җиһазландырылды. Шулай ук музей-йортка күп кенә яңа документлар куелды.

Иж чишмәләрен өйрәнү

1903 нче елда ачылган Иж минераль чишмәләре фәнни яктан аз тикшерелгәннәр иде. Бары тик 1927 нче елда гына алар Казан Дәүләт Университетының профессоры З. Н. Блюмштейн тарафыннан системалы рәвештә өйрәнелә башлады.

Казан Дәүләт Университеты янында чыга торган „фәнни язмалар“ журналының 1939 нчы елда чыккан китабында профессор Блюмштейн „Иж минераль чишмәләрен өйрәнү“ дигән хезмәтендә үзенең системалы рәвештә алып барган күзәтүләренә йомгак ясады.

Хәзер Куйбышев гидроузелы һәм, аеруча, Кама елгасында Соколка плотинасы төзелү уңае белән, Иж һәм Кама елгаларының күтәрелүе Иж чишмәләренең химия составына нинди үзгәреш кертер дигән мәсьәлә кызыклы проблема булып тора. Шушы уңай белән профессор Блюмштейн суның биеклеген гидрометрик яктан даими рәвештә үлчәүләрне һәм көн саен алынган суга лабораториядә физик һәм химик яктан анализ ясауны оештырды.

Шулай ук Иж скважинасыннан ерак булмаган минераль чишмәләр дә өйрәнелә: Фәнни работник Е. С. Нагербина Иж минераль чишмәләре группасының радио активлыгын һәм тозлы чишмәләрне өйрәнү буенча фәнни хезмәт бастырып чыгарды.

Допризывниклар арасында эшләү

ВКП(б) ның Биектау райкомының хәрби бүлеге район Хәрби Комиссариаты белән берлектә оборона эшен җәнләндырү буенча күп кенә чаралар үткәрә.

Районның барлык 20 авыл советында да хәрби эшне өйрәнү буенча түгәрәкләр оештырылды. Түгәрәкләргә допризывниклар тартылды. Түгәрәкләргә запастагы командирлар җитәкчелек итәләр. Һәрбер түгәрәккә политик-масса эшләрен алып бару өчен политруклар беркетелде. Допризывниклар һәр көнне 2 сәгать хәрби белемне өйрәнәләр. 5 көнгә бер тапкыр политзанятие үтәлә.

Түгәрәкләр арасында хәрби эшне яхшы үзләштерү өчен социалистик ярыш җәелдерелде. Биектау районының допризывниклары Арча районы допризывникларын чираттагы призывка үрнәкле рәвештә хәзерләнү буенча социалистик ярышка чакырдылар.

***

Беренче Май районының допризывниклары арасында Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенә булачак чираттагы призывны үрнәкле каршылау өчен ярыш җәелдерелде. Чирмешән авыл советының допризывниклары Лашман авыл советы допризывникларын социалистик ярышка чакырдылар. Допризывниклар Осоавиахим сафларына член булып керергә, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең XXII еллыгына һәрбер допризывникның өчтән дә ким булмаган оборона значогы алуына ирешергә, беренче мартка кадәр допризывниклар арасында укый-яза белмәүне һәм аз укый-яза белүне бетерергә дигән йөкләмә алдылар.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЫНЫҢ
Юллар Санитария-Гигиена лабораториясе
(Казан, Посадский урамы, 10)
һәр төрле азык продуктларын, ашларны, суларны һәм эчемлекләрне химик-бактериологик анализлау
һәм корсак тифы, тигелле тиф, бруцеллез бациллаларына карата химик-бактериологик анализ эшләре үткәрү, шулай ук фәнни тикшеренү эшләре үткәрү буенча барлык кызыксынган оешмалар һәм учреждениеләр белән
ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ
2719—2—1

Н. Э. БАУМАН ИСМЕНДӘГЕ
КАЗАН ЗООВЕТЕРИНАРИЯ ИНСТИТУТЫ
ИНСТИТУТКА ХӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА
6 айлык курсларга укучылар ала
Хәзерлек курсларына тәгәлләнгән урта белемле (ун еллык мәктәп, техникум, рабфак тәгәлләгән) кешеләр алыналар.
Хәзерлек курсларында укулар производстводан аерылып һәм аерылмыйча алып барыла.
ВУЗ ларга керү өчен сорала торган документлар белән, гаризалар 1940 нчы ел 20 нче гыйнварга кадәр алына. Казан, Ершов кыры, 10. Зооветеринария институты. Телефон 5—88.
2673—2—2

Татнаркомздрав Дәүләт Санитария инспекциясенең
САНИТАРИЯ-ГИГИЕНА ЛАБОРАТОРИЯСЕ
һаваны, туфракны, суларны, чишмә суларын, азык продуктларын, ашларны һәм башкаларны санитария-химик һәм бактериологик анализлау эшләре үткәрү буенча 1940 нчы ел өчен
ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ
Лаборатория санитария консультацияләре бирә, шулай ук коммуналь һәм промышленность төзелеше проектлары буенча һәм санитария-гигиена мәсьәләләре буенча заключениеләр бирә. Казан, Бутлеров урамы, 16. Телефоннар: 10—39 һәм 43—86.
2661—2—2

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автоуправлениенең
бензин һәм майлау материаллары конторасы
шәһәрдәге һәм районнардагы бензин алучыларның кулларындагы
ТАЛОННАРНЫ ТЕРКӘҮ ҮТКӘРӘ
Шәһәрдәге бензин алучыларның талоннарын теркәү шушы ел 8 нче гыйнварга, ә районнардагы бензин алучыларның талоннарын теркәү 13 нче гыйнварга кадәр дәвам итә.
Бензин һәм майлау материаллары станциясенең Автотранспорт наркоматына күчерелүе уңае белән, күрсәтелгән срокта теркәлмәгән талоннар гамәлдән чыккан дип исәпләнәчәк.
Бензин талоннарын теркәтергә килүчеләрдән ышаныч кәгазе сорала. 5—3—3

15 нче гыйнвар, кич 6 сәгатьтә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетының 43 нче бүлмәсендә биология факультеты гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм биология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен Д. И. ОСПИСОВ тарафыннан, „Ак куян“ дигән темада халык алдында
ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ
үткәрелә
Рәсми оппонентлар: доцент А. Я. Соколов һәм доцент А. И. Шмидтов.
Утырышка Казан шәһәре БУЗ ларының фәнни работниклары чакырылалар.
29—1

• **ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ**
8 нче гыйнварда, шулай ук 9 нчы гыйнварда көндез һәм кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Бүген талон 71.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ
12 нче гыйнварда көндезге спектакльгә коллектив заявкалар буенча килүчеләргә (100 билеттан ким булмаганда) 50 процент ташлама ясала.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының гастрольләре.
ЯҢА ЕЛ КАРНАВАЛЫ
Бөтен труппа катнаша.
Орденлы АЛЛИ-ВАД ның һәм ВЕРА МИРОВАНЫҢ соңгы гастрольләре.
12 нче гыйнварга кадәр һәр көн 11 сәгатьтә, 2 сәгать 30 минутта һәм кич 8 дә
ЦИРК УЕННАРЫ
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

КИРӘК:
Даими эшкә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ БОНДАРЬЛАР һәм КАССИРЛАР. Хезмәт хакы прогрессив тәртиптә түләнә. Казан, Аргы Устье, 2 нче нефтебаза. 28—2—1

Центроэлектромонтажның Казан конторасына, Казанда һәм районнарда эшләү өчен ЭЛЕКТРОСЛЕСАРЬЛАР һәм БАРЛЫК РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР.
Кирәк булса, тулай торакта урын бирелә. Башка шәһәрләрдәге монтаж пунктларына китеп эшләүчеләргә командировка акчасы да бирелә. Казан, Банк урамы, 13. Кадрлар бүлегенә килергә 30—3—1

Селхозснабның Казан базасына даими эшкә ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР, БУХГАЛТЕРЛАР һәм КАРТОТЕКАЧЫЛАР. Казан, Володарский урамы, 8. Баш бухгалтерга мөрәҗәгать итәргә. 25—2—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 8 нче гыйнварда
КЫЮ КЫЗЛАР
Бүген талон 91.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез 10 сәгатьтә ХӘЗИНӘЛӘР АТАВЫ һәм башка сеансларда ПАРТБИЛЕТ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ Көндез 10 сәгатьтә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Көндезге сеансларда ФЕДЬКА Кич УКЫТУЧЫ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН
„ПИОНЕР“ 11, 2, 4, 5-45 8, һәм 10-15 тә	Көндез һәм кич БӨЕК ГРАЖДАНИН (икенче сериясе) Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс ВАРЯ КАПИТАН
„РОТ-ФРОНТ“ 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	Бөек бүләк
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	Укытучы

Даими эшкә квалификацияле
БОНДАРЬЛАР КИРӘК
Хезмәт хакы прогрессив эш башыннан түләнә. Казан, Аргы Устье, 2 нче номер Нефтебаза (шәһәргә автобус белән йөрелә).
2571—2—2

Казан Мехкомбинаты идарәсенә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ МАШИНИСТКАЛАР кирәк Яна бистә, Кызыл Татарстан урамы, 3, бүлмә № 13. 2652—5—4